Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

В.М. Усманов

БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАТАР ЭПИГРАФИК ҺӘЙКӘЛЛӘРЕ

Уфа

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

Г.ИБРАҺИМОВ исем. ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

В.М. Усманов

БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАТАР ЭПИГРАФИК ҺӘЙКӘЛЛӘРЕ

УФА

Казан
2021

УДК 930.271
ББК 63.2
У 74

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә

Фәнни редактор
филология фәннәре кандидаты *И.Г. Гомәров*

Рецензент
филология фәннәре кандидаты, доцент *А.М. Ахунов*

Усманов В.М.
У 74 Башкортстан Республикасы татар эпиграфик һәйкәлләре: Уфа. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 44 б.
ISBN 978-5-93091-356-9

Китапта Уфа шәһәренең «Гофран» мәчете тирәсендәге мөселман зиратында сакланып калган иллегә якын ташъязма истәлек турында мәгълүмат туплап бирелә, гарәп графикасындагы текстлар гамәлдәге язуга күчерелеп, шәрех-аңлатмалар белән урнаштырыла.

Хезмәт Идел-Урал төбәге тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче галимнәр, гомумән татар халкының тарихи үткәне белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

УДК 930.271
ББК 63.2

ISBN 978-5-93091-356-9

© Усманов В.М., 2021;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2021

КЕРЕШ

Уфа шәһәре – күпмилләтле Башкортстан Республикасы башкаласы. Археологлар раславынча, бик борынгы чорларда ук Агыйдел елгасы буенда күчмә һәм утрак тормыш алып барган «дала» һәм «урман» төрки һәм фин-угор кабиләләр үзара аралашып гомер кичергән. Бу шәһәр географик яктан зур елгалар арасындагы биек урынга уңайлы урнашу сәбәпле, элеккеге чорларда ышанычлы ныгытма һәм халыкара сәүдә базары вазифаларын үтәгән.

Уфа шәһәре биләмәсендә ничә борынгы зират булуы бүген фәндә төгәл мәгълүм түгел. Безнең уебызча, биредә Дәште Кыпчак яисә Нугай Урдасы дәверендә дә иске каберлекләр булган дияргә нигез бар. Инде «эзе» дә калмаган шундый каберлекләрнең берсе хәзер «Пеләш тау» (Лысая гора) дип аталган урында булган. Кызганыч ки, аерым бер сәбәпләр аркасында, тарихның ул чорларыннан безнең көннәргә кадәр бер эпиграфик һәйкәл дә килеп җитмәгән. Уфа шәһәрендәге безгә мәгълүм иске каберлекләр, нигездә, XIX – XX гасыр башларына карыйлар. Аларның беренчесе Диния нәзарәте, икенчесе хәзерге «Гофран» мәчете янәшәсендә урнашкан. Шулай ук «Җиңүнең 50 еллыгы» исемендәге парк биләмәсенең бер өлешендә дә элек мөселман зираты булганлыгы мәгълүм.

«Гофран» мәчете янәшәсендәге зиратта безнең тарафтан XIX йөз азагы – XX гасыр башына мөнәсәбәтле һәм гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган 50 эпиграфик һәйкәл исәпкә алынды. Бу төр эпитафик ядкярләр арасында узган гасырларда мөфти вазифаларын башкарган Габдессәлам бине Габдеррәхим, Габделвахид Сөләйманов, Мөхәммәдьяр Солтанов, Ризаэддин бине Фәхреддин, казый Гыйнаятулла Кабкаев, ахун вә мөдәррис Хәйрулла Госман, матбагачы Ильяс бине Әхмәдшаһ Борагани, руханилар Әхмәд ибне ахун Мәүлед, имам Әхмәдшакир, Уфаның беренче мәчетендә азанчы вазифаларын үтәгән Хәйреддин бине Һашим улы Сөбханколов, хаҗи Исламгали бине Җиһаншаһ, тәрҗемәче Закир Ишмөхәммәдов, зыялы морзалар катламыннан Мөхәммәдрәхим бине Салих, Сөләйман Дәүләткилдиев, Салих Йәникеев, Мөхәммәдгәрәй Терегулов, Мөхәммәдкәрим бине Салих Биглов, сәүдәгәр Гайфулла Галиулла улы Госмани кебек күренекле

шәхесләрнең истәлекләренә куелган ташлар тарихи ядкярләрне өйрәнү һәм саклау җәһәтеннән аеруча игътибарга лаек.

Эзләнүләр күрсәткәнчә, әлеге ташъязмаларның төп өлеше Уфа кятибләре тарафыннан язылган. Аерым бер ташларда аларның култамгалары да бар. Шул ук вакытта Уфадан читтә яшәгән таш язучы каллиграфлар кулы белән башкарылганнары да очрый, мәсәлән: Казаннан – Габделбарый әл-Баруди, Стәрлебаштан – Габдеррәхим бине Гали хәлфә (Чалатай бабай), Оренбург Каргалысыннан – Сәйфеддин бине Хафизеддин һ.б.

Элек Уфада алты мәчет булуы мәгълүм. Шул гыйбадәтханәләрнең кайберләре каршында мәдрәсәләр дә эшләп килгән. Әлбәттә, биредәге «Галия», «Госмания», «Хөсәения» кебек мәшһүр уку йортларында да каллиграфия һәм таш язу сәнгате дәресләренең югары дәрәҗәдә укытылганлыгы билгеле.

Безнең тарафтан тикшерелгән ташъязмаларның күпчелеге татар эпиграфикасының күпгасырлык традицияләренә таянып эшләнгән. Алар арасында классик нәсех яисә сөлес язуы белән нәкышьләнгәннәре төп өлешне тәшкил итә. Шулай ук нәстәгълик язуында башкарылган берничә ташъязма да хәзерге көннәргәчә сакланган.

Шунысын да искәртү мөһим: куфи яисә рокга кебек хөсне хат үрнәкләре бу җирлектә, гомумән, очрамый.

Уфа шәһәре тау башында урнашса да, аның Оребургтагы кебек керәч (известьняк) ташына бай үз «Гребенни тавы», яисә Яшергандагы кебек «Таш тавы» карьерлары булмаган. Шул сәбәпле, кабер ташларын ясау өчен таш чимал төрле төбәкләрдән китерелгән дип уйларга кирәк. Берничә ташъязма урындагы ком ташыннан, кайберләре (мигъмари корылма кебекләре) Урал мәрмәреннән яисә гранитыннан ясалган. Аларның күбесе Европа-рус архитектурасы үрнәкләренә охшатып «Евразия стиле»ндә башкарылган.

Гасырлар, еллар үткән саен эпиграфик һәйкәлләр акрынлап табигый рәвештә җимерелеп юкка чыга бара. Әлбәттә, бу мирасны саклап калу юлларының берсе – аларны өйрәнеп, фәнни җыентыклар, китаплар нәшер итү. Уфа шәһәрендәге татар язулы эпиграфик истәлекләр хакындагы әлеге хезмәтне дә әнә шул юлдагы бер адым дияргә мөмкин.

Венер Усманов,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре

ТАШЪЯЗМАЛАР

1. Мөфти Габдессәлям бине Габдеррәхим каберенә куелган таш, 1840 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

اوشبو قبر	*Ошбу кабер*
محکمهء شرعیهء اورنبور	*мәхкәмәи шәргыяи Оренбур-*
عیه ده مفتی عبدالسلام	*гыядә мөфти Габдессәлям*
بن عبد الرحیم بن عبد الرحمن	*бине Габдеррәхим бине Габдеррахман*
مرقدیدور میلا	*мәркадедер миля-*
دی ایله ۱۸۲۵ نچی	*-ди илә 1825 нче*
یلده مفتی نک مقامنه کیچوب	*елда мөфтинең мәкаменә*[1] *кичеб*
یاشی یتمش که یاقن	*яше йетмешкә якын*
بولعانده میلادیچه	*булганда милядичә*
۱۸۴۰ نچی یلده عنوار	*1840 нчы елда гыйнвар-*
ده هجری ۱۲۵۵ نچی یلده	*-да һиҗри 1255 нче елда*
ذی الحجه اینده دار	*зөлхиҗҗә аенда дар-*
البقایه رحلة ایتدی	*-елбәкая рихләт итде*

[1] *Мәкам* – дәрәҗәсе, торган урыны.



1=А (алгы як)

2=Б (уң ягы)

2=Г (сул ягы)

2. Мөфти Габделвахид Сөләйманов каберенә куелган таш, 1862 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

…	…
عبد الوحد مفتى …	*Габделвахид мөфти …*
طرحان سليمانف رحمه …	*тархан Сөләйманов рәхәмәһе …*
٢٢ يل مفتى الوب	*22 ел мөфти улыб*

Уң ягында (уйма язулы):

و عن عمر رضى الله عنه	*вә ган Гомәр разый Аллаһу ганһу*
عزّ الدنيا بالمال	*гыйззә әд-дүнйа бил-мали*
و عز الاخرة بصالح الاعمال	*вә гыйззә әл-ахирәт би-салих әл-әгъмали*[1]
عبد البارى بارودى قلميله يازلدى	*Габделбарый Баруди каләмилә язылды*

[1] Гомәр разый Аллаһу ганһедән: дөнья мал белән, ахирәт изге гамәлләр белән күркәм.

Арткы ягында (уйма язулы):

۷۶ یاشنده	*76 яшендә*
بو منزل اخرته نازل اولدی	*бу мәнзил ахирәтә назил улды*
صَفر الحیرننک ۱۹ نده ۱۲۷۹سنه	*сафар әл-хәйрнең 19 нда 1279 сәнә*
دورتنچی اعوست ده ۱۸۶۲ سنة میلادیه	*дүртенче август да 1862 сәнәтә милядия*

Сул ягында (уйма язулы):

و عن ابی بکر الصدیق	*вә ган Әбү Бәкер ас-сыйддыйк*
من دخل القبر بلا زاد	*мән дәхәлә әл-кабрә биля зад[ин]*
فکأنما رکب البحرَ	*фә-кәәннәма рәкәбә әл-бәхрә*
بلا سفینة	*биля сәфинәт[ин]*[1]

Үлчәмнәре: 26×40×145 см.
Кятиб – Габделбарый Баруди.

3. Арыслангәрәй Кәлимулла улы каберенә куелган таш, 1883 ел

Алгы ягында (калку язулы):

الموت باب و کل الناس داخله	*Әл-мәүт баб вә күллү-н-нәс дахәләһә*[2]
تاریخ هجریه ایلان	*Тарих һиҗрия илән*
۱۳۰۱ نچی سنه ده ربیع الأ	*1301 нче сәнәдә рәбигыль-әү-*
ول ننک بشنچی یومنده	*-вәлнең бишенче йәүмендә*
تاریخ مسیحیه ایلان ۸۳ نچی	*тарих мәсихия илән 83 нче*
یلده ۲۳ نچی دیکابرده	*йылда 23 нче декабрьдә*
ارسلانکری کلیم الله	*Арыслангәрәй Кәлимулла*

Сул ягында (уйма язулы):

کیلوب قبرم زیارة ایدن اخوان	*Килеб каберем зиярәт идән ихван,*

Уң ягында (уйма язулы):

قیله روحمه بر فاتحه احسان	*Кыла рухыма бер фатиха ихсан*

---

[1] Әбү Бәкер әс-сыйддыйк сөйләгәннәрдән: кабергә рухи азыксыз керүче диңгезгә корабсыз чыгучыга тиң.

[2] Үлем ул – ишек һәм һәркем ул ишектән керәчәк.

3=А

4=А

4=Г

4. Морза Сөләйман Дәүләткилдиев кызы Зөләйха каберенә куелган таш, 1886 ел

Алгы ягында (калку язулы):

مرحومه مرقد	*Мәрхүмә мәркадь*[1]
زليحه سليمان مرضهَ	*Зөләйха Сөләйман морза*
دولت كيلديف	*Дәүләткилдиев*
قزى وفات قرق	*кызы вафат кырык*
ياشنده محمد جان	*яшендә, Мөхәммәдҗан*
مرضه بيكلوف	*морза Биглов*
حلالى ايول ٣١ نده	*хәляле июль 31 ндә*
١٨٨٦ سنه ده	*1886 сәнәдә*

[1] *Мәркадь* – кабер.

Арткы ягында (калку язулы):

تنده جانم نچه کون مهمان ایکاندر بلمدم	*Тәндә җаным ничә көн, миһман икәндер белмәдем;*
اوتدی عمرم باروسی ویران ایکانن بلمدم	*Үтде гомерем, барысы вәйран икәнен белмәдем.*
عره اولمه بو جهان نک مال ملکه جاهنه	*Гарра*[1] *улма бу җиһанның мал-милеге җаһына*
منک یشارسنک اخری دوشمک اولم نک جاهنه	*Мең яшәрсең, ахры – дөшмәк үлемнең җаһына*

Сул ягында (калку язулы):

اوتدی کچدی دوران سیران بنی کور	*Үтде, кичде дәүран сәйран бәне күр,*
بنی کورب کور یاراغن سز ده کور	*Бәне күреб гүр ярагын сез дә күр.*

Үлчәмнәре: 16×32×125 см.

5. Идрис бине Әбүбәкер каберенә куелган таш, 1887 ел

5=А

[1] *Гарра* – бозыклык, әхлакый түбәнлек.

Алгы ягында (калку язулы):

تاريخ رومى ايلان	*Тарих руми илән*
١٨٨٧ نچى يلده ٢٥ نچى اپريل ده	*1887 нче елда 25 нче апрельдә*
ايدرس بن ابو بكر كل نفس ذائقة	*Идрис бине Әбү Бәкер көллү нәфсин заикател-*
الموت يا وقفًا بقبرى متفكّرا بامرى	*мәүт*[1]*. Йа вакыйфән би-кабри мөтәфәккирән би-әмри*
بالامسى كنت مثلك غدا تصير مثلى	*бил-әмси күнтү мисликә гадән тәсайир мисли*[2]
بنم قبرم زيارت ايدن انسان قيلسه	*Бәнем кабрем зиярәт идән инсан, кылса*
روحمه بر فاتحه احسان	*рухыма бер фатиха ихсан*

6. Мөәззин Һашим Сөбханкулов улы Хәйреддин каберенә куелган таш, 1891 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

كفى بالموت واعظا	*Кәфә бил-мәүти вагыйзән*[3]
مرقد شريف	*мәркадь шәриф*
حَيرالدين بن هاشم اوعلى	*Хәйреддин бине Һашим углы*
سبحانقولف ١٨٤٥ سنه	*Сөбханколов 1845 сәнә*
اوفينك برنچى مسجد جامعده	*Өфенең беренче мәсҗед җамигъда*
مؤذين لک سرير جلوس ايدوب	*мөәззинлек сәрир җөлүс идеб*[4]
١٨٩١ سنهء ميلاديه اوكتابرنک۶ كوننده	*1891*[5] *сәнәи милядия октябрьнең 6 көнендә*

---

[1] *Көллү нәфсин заикател-мәүт* – Һәрбер җан үлем тәмен татып караячак.

[2] *Йа вакыйфән би-кабри, мөтәфәккирән би-әмри, бил-әмси күнтү мисликә, гадән тәсайир мисли* – Әй, каберем янына туктаган, Аллаһының әмере турында уйлаган [кеше]! Кичә мин синең кебек идем, иртәгә син дә минем кебек булырсың.

[3] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.

[4] *Мөәззинлек сәрир җөлүс идеб* – Мәзинлек вазыйфасын башкарып.

[5] 1898 ел булуы да ихтимал.

6

7=А

7. Хәйреддин кызы Өммегөлсем каберенә куелган таш, 189[1] ел

Алгы ягында (уйма язулы):

المرحومة ام كلثم	*Әл-мәрхүмәт Өммегөлсем*
بنت خيرالدين زوجة	*бинте Хәйреддин зәүҗәте*[1]
عثمان تيريعولوف توفت	*Госман Терегулов тәүвәффәт*[2]
١٨٩١ سنت ٢٧ ياشنده ...	*189 ...*[3] *сәнәти 27 яшендә ...*

[1] *Зәүҗәте* – хатыны.
[2] *Тәүвәффәт* – вафат.
[3] 1898 ел булуы да ихтимал.

8. Габдеррәшид кызы Сәгадәт каберенә куелган таш, 1891 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

لا اله الا الله محمد رسول الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ*[1]
اوشبو قبرده مدفونة	*ошбу кабердә мәдфүнәт*
سعادت دامنه عبدالرشيد	*Сәгадәт дамәнә*[2] *Габдеррәшид*
قزى محمدشريف سلطانف	*кызы Мөхәммәдшәриф Солтанов*
جماعتى سكسان بش ياشنده	*җәмәгате сиксән биш яшендә*
دار البقايه رحلت قلدى جنان حق تعالى رحمت ايلسون	*дарелбәкая рихләт кылды*[3] *җәнан Хак* *Тәгалә рәхмәт әйләсен*

Сул ягында (уйма язулы):

تاريخ ميلاديه ايله ١٨٩١ سنه ده ١٠ نچى مارطده	*Тарих милядия илә 1891 сәнәдә* *10 нчы мартда*

9. Салих Йәникеев кызы Биби-Фатыйма каберенә куелган таш, 1895 ел

Алгы ягында (калку һәм уйма язулы):

لا اله الا الله محمد رسول الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ*
بو قبرده بيبى فاطمه صالح	*бу кабердә Биби Фатыйма Салих*
ينكييف قزى و محمدكراى	*Йәникеев кызы вә Мөхәммәдгәрәй*
مرزا تيريعولوف اهليه سى	*морза Терегулов әһлиясе*[4]
۶۵ ياشنده وفات ۲۴ نچى	*65 яшендә вафат 24 нче*
مارطده ۱۸۹۵ سنه ده دفن	*мартда 1895 сәнәдә дәфен*
اولندى الله رحمت ايلسون امين	*улынды*[5] *Аллаһ рәхмәт әйләсен амин*

---

[1] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе

[2] *Дамәнә* – намуслы, гыйффәтле.

[3] *Дарелбәкая рихләт кылды* – бакый дөньяга күчте.

[4] *Әһлиясе* – хатыны.

[5] *Дәфен улынды* – җирләнде.

8=A

9=A

9=Г

9=A=a

Уң ягында (уйма язулы):

داعی اولەسز مونکا ای مؤمنان	*Дагый[1] уласыз моңа әй, мөэминән*
کمیسه باقی دَکلدر بو ...	*Кемисә бакый дәгелдер бу [гомер]*

Сул ягында (уйма язулы):

... زیارت ایدان اخوان	*[Бәнем каберем] зиярәт идән ихван*
قیلالر روحمەَبر فاتحه احسان	*Кылалар рухыма бер фатиха ихсан*

10. Миһран кызы Шәмсеруй каберенә куелган таш, 1897 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

لا اله الا الله محمد رسول الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ[2]*
المرحومة شمس روی	*әл-мәрхүмәт Шәмсеруй*
بنت مهران زوجة ارسلان	*бинте Миһран зәүҗәте[3] Арслан-*
کرای تیریعولوف توفت	*-гәрәй Терегулов тәүвәффәт*
سنة ١٨٩٧	*сәнәти 1897*

11. Фәйрузшаһ кызы Һәдия каберенә куелган таш, 1898 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

کل شی هالك الا وجهه	*Көлли шәййе һаләк иллә вәҗһәһү[4]*
بو مقبره ده اوفا	*бу мәкъбәрәдә[5] Уфа*
اقروژنی صودنده	*окружной судында*
ترجمان اولوب تورمش	*тәрҗеман улыб тормыш*

---

[1] *Дагый* – догачы.

[2] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлуллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.

[3] *Зәүҗәте* – хатыны.

[4] *Көлли шәййе һаләк иллә вәҗһәһү* – Аллаһының йөзеннән башка һәрнәрсә һәлак булучыдыр («Касас» сүрәсе, 88 аять).

[5] *Мәкъбәрә* – кабер.

10=А

11=А



ذاكر اشمحمدوفنك	*Закир Ишмөхәммәдовның*
جماعتى هَديه فيروزشاه	*җәмәгате Һәдия Фәйрузшаһ*
قزى ٣٠ ياشنده ١٨٩٧ سنه ده	*кызы 30 яшендә 1897 сәнәдә*
٢٩ نچى اوكتابرده وفات	*29 нчы октябрьдә вафат*
الله تعالى رحمت ايلسون	*Аллаһы Тәгалә рәхмәт әйләсен*
مرحومه نک قزلرندن اونك ...	*мәрхүмәнең кызларыннан уң [тарафында]*

Сул ягында (уйма язулы):

... فاطيمه ٣ ياشنده	*... Фатыйма 3 яшендә*
و صول طرافنده ثانيه ٨ ياشنده	*вә сул тарафында Сания 8 яшендә*

Уң ягында (уйма язулы):

كيلوب قبرم زيارة ايدن اخوان	*Килеб каберем зиярәт идән ихван,*
قيله روحمه بر فاتحه احسان	*Кыла рухыма бер фатиха ихсан*

12. Ризаэддин бине Фәхреддин улы Хәсән каберенә куелган таш, 1898 ел[1]

Алгы ягында (уйма язулы):

حسن بن رضا الدين	*Хәсән бине Ризаэддин*
بن فخرالدين فى توفى	*бине Фәхреддин фи тәвәффи*[2]
۱۴ محرم عام	*14 мөхәррәм гам*[3] ...
...	...

13. Илек шәһәреннән 1864 елда Уфа каласына килгән кешенең каберенә куелган таш, 1899 ел

Беренче ягында (калку язулы):

ايلك شهر ...	*Илек шәһәр ...*

Икенче ягында (калку язулы):

... موت قريب	*... мәүт кариб*

Өченче ягында (калку язулы):

۱۸۹۹ نچى سنه اوكتبر ننک	*1899 нчы сәнә октябрьнең*
۲۷ سنده ...	*27 сәнәдә ...*

Бишенче ягында (калку язулы):

اورنبورع طرافلرنده مشهور ...	*Оренбург тарафларында мәшһүр ...*

Алтынчы ягында (калку язулы):

اولدى ايرشدى امر ربانى	*улды ирешде әмер раббани*

---

[1] 1902 ел булуы ихтимал.
[2] *Тәвәффи* – вафат.
[3] *Гам* – ел.

12=A

13

13

13

13

Җиденче ягында (калку язулы):

کلمش ۱۸۵۴ نچی سنه ۲ نچی فبرال ده …	*килмеш 1854 нче сәнә 2 нче февральдә ...*

Сигезенче ягында (калку язулы):

که تسلیم ایلدم حقعه …	*Ки тәслим әйләдем Хакга ...*

Үлчәмнәре: 29×29×175 см.

14. Калимулла кызы Фатыйма каберенә куелган таш, 1899 ел

Алгы ягында (калку язулы):

توكلى عَلى الله	*Тәвәккәлә галә Аллаһи*[1]
المرحومة فاطيمه	*әл-мәрхүмәт Фатыйма*
بنت كليم الله زوجة	*бинте Кәлимулла зәүҗәте*[2]
باطرگراى ينكيف	*Батыргәрәй Йәникәев*

Сул ягында (калку язулы):

توفت ١٨٩٩	*тәвәфәт*[3] *1899*

Уң ягында (калку язулы):

٧١ ياشنده	*71 яшендә*

15. Гайнелхәят каберенә куелган таш, 1875–1900

Алгы ягында (уйма язулы):

لا اله الا الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ*
محمد رسول الله	*Мөхәммәд рәсүлүллаһ*[4]
بو قبرده عين الحيات	*бу кабердә Гайнелхәят*
تو...رالدين	*ту... [Хәйреддин]*
ينكييف ١٨٧٥ سنه	*Йәникәев 1875 сәнә*
طوعب ١٩٠٠ سنه وفات	*тугыб 1900 сәнә вафат*

---

[1] *Тәвәккәлә галә Аллаһи* – Аллаһы Тәгалә хозурына тапшырылды.

[2] *Зәүҗәте* – хатыны.

[3] *Тәвәфәт* – вафат.

[4] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.



14=А

15=А

16=А

16. Ибраһим Йәникеев улы Хәйреддин каберенә куелган таш, 1901 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

لا اله الا الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ*
المرحوم حير الدين	*Әл-мәрхүм Хәйреддин*
بن ابراهيم	*бине Ибраһим*
ينكييف توفى	*Йәникәев тәвәффа*

Арткы ягында (уйма язулы):

فى سنة ١٩٠١	*фи сәнәти 1901*
و فى مه شوال	*вә фи маһ шәүвәл*[1]
٦٠ ياشنده	*60 яшендә*
نور الله مرقده	*нәүвәрә Аллаһу мәркадәһә*[2]

---

[1] *Фи сәнәти 1901 вә фи маһ шәүвәл* – 1901 елның шәүвәл аенда.
[2] *Нәүвәрә Аллаһу мәркадәһә* – Аллаһы аның каберен нурландырсын.

17. Исламгали Җиһаншаһ улы каберенә куелган таш, 1904 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

اوفى كوبرنه	*Уфа губерна-*
سى بورى اويازى	*сы Бөре өязе*
سيبى اولى حه جى	*Сиби авылы хаҗи*
الحرمين ايسلام	*әл-хәрәмәен Ислам-*
على بن جهان شا	*-Гали бине Җиһанша*

Уң ягында (уйма язулы):

١٩٠٤ نچى سنه ٢٨ نچى مارط	*1904 нче сәнә 28 нче март*

18. Әхмәди кызы Фатыйма каберенә куелган таш, 1830–1904

Алгы ягында (калку язулы):

كل شى هالك	*Көллү шәйин һаликүн*
الاوجهله الحكم	*иллә вәҗһәһү ләһү әл-хөкму*
و اليه ترجعون	*вә иләйһи түрҗәгунә*[1]
بومقبرده مدفون	*бу мәкъбәрәдә*[2] *мәдфүн*[3]
فاطمه بنت ملا احمدى	*Фатыйма бинте мулла Әхмәди*
ابن احون مولود	*ибне ахун Мәүлүд*
زوجهء مؤذين	*зәүҗәи*[4] *мөәззин*
حيرالدين بن هاشم	*Хәйреддин бине Һашим*

Арткы ягында (калку язулы):

وجودى ١٨٣٠ سنه	*вөҗүде*[5] *1830 сәнә*
وفات١٩٠٤ سنه	*вафат 1904 сәнә*
٧٤ ياشنده	*74 яшендә*
عفر الله ذنوبها	*гафәрә Аллаһу зөнубиһа*
وسترعيوبها	*вә сәттәрә гуюбиһа*[6]

---

[1] *Көллү шәйин һаликүн иллә вәҗһәһү ләһү әл-хөкму вә иләйһи түрҗәгунә* – Аллаһының йөзеннән башка һәрнәрсә һәлак булучыдыр, һәр эштә хөкем Аллаһуга хастыр, вә хөкем ителү өчен Аллаһуга кайтырсыз («Касас» сүрәсе, 88 аять).

[2] *Мәкъбәрә – кабер*.

[3] *Мәдфүн* – җирләнгән.

[4] *Зәүҗәи* – хатыны.

[5] *Вөҗүде* – туган елы.

[6] *Гафәрә Аллаһу зөнубиһа вә сәттәрә гуюбиһа* – Аллаһ гөнаһларын гафу итсен, гаепләрен кичерсен.



17=А

18=А

19=А

19. Сөләйман Дәүләткилдиев кызы Өммегөлсем каберенә куелган таш, 1828–1905

Алгы ягында (уйма язулы):

كل نفس ذائقة الموت	*Көллү нәфсин заикател-мәүт*[1]
ام كلثوم بنت سليمان دولت كيلديف	*Өммегөлсем бинте Сөләйман Дәүләткилдиев*
باطركراى بن شاهنكراى توكلى زوجه سى	*Батыргәрәй бине Шаһингәрәй Тәүкили зәүҗәсе*
١٨٢٨ ١٩٠٥	*1827–1905*
انّما الدنيا فنا ء ليس للدّنيا بقاء	*Иннәма әд-дөнья фәнаүн, ләйсә ли-д-дөнья бакаун.*
انّما الدنيا و ما فيها كنسج العنكبوت	*Иннәма әд-дөнья вә ма фиһа кә-нәсҗи-л-ганкәбут*[2].

---

[1] *Көллү нәфсин заикател-мәүт* – Һәрбер җан үлем тәмен татып караячак.

[2] Гали бине Әбу Талиб сөйләгән шигъри юлларның үзгәртелгән варианты: *Дөнья тиз узучан, фани; анда мәңгелек [бернәрсә дә] юк. Дөньяның барча эше үрмәкүч үргән пәрәвез сыман.*

 20=A 21=A

20. Мифтахеддин улы Сабирҗан каберенә куелган таш, 1906 ел

Алгы ягында (калку язулы):

کفی بالموت واعظا	*Кәфә бил-мәүти вагыйзән*[1]
المرحوم صابرجان	*әл-мәрхүм Сабирҗан*
بن مفتاح الدين	*бине Мифтахеддин*
يوسوپف توفى	*Йосыпов тәвәффә*
سنة ١٩٠٦	*сәнәти 1906*
…	...

21. Зөфәр кызы Галия каберенә куелган таш, 1906 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

عليه بنت زفر بن	*Галия бинте Зөфәр бине*
ملا احمد شاكر	*мулла Әхмәдшакир*
توفيت فى ١٣٢٤	*тәвәффият фи 1324*
سنه و فى ٢ ربيع	*сәнә вә фи 2 рәбиг-*
الاوّل ...	*-ыль-әүвәл ...*

[1] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.

22=A

22. Ахунд мөдәррис Хәйрулла Госманның каберенә куелган таш, 1907 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

اوفا شهرنده ۲۰ سنه امامت و تعليم و تاليف ايله مشغول اولان احوند و مدرس
خير الله عثمان نڭ مقبره سيدر. تاريخ ولادة ۱۸٤۷ سنه م. ۸ اوكتابر تاريخ وفات
۱۹۰۷ سنه م. ۱ نويابر رحمه الله رحمة واسعة

موتى بزنى آ غلاب نا ذات مدفون اولدى بو يره
فوتكزنى اويلاغانده جمله كوزدن ياش كيله
دنياده توردقچه علمڭ همتڭ فضلڭ ايله
خدمت ايتدك هم چالشدڭ ملتكنى تنويره
عمر كنى ايتدڭ حصر تدريس تاليف تحريره

Уфа шәһәрендә 20 сәнә имамәт вә тәгълим вә тәэлиф илә мәшгуль улан ахунд вә мөдәррис Хәйрулла Госманның мәкъбәрәседер. Тарихе вәлядәт 1847 сәнә м. 8 үктәбер, тарихе вафат 1907 сәнә м. 1 нуябер рәхәмәһу Аллаһу рәхмәтән васигатән[1]

Мәүте, безне аглаб на зат мәдфүн улды бу йирә,
Фәүтеңезне[2] *уйлаганда җөмлә күздән йәш килә.*
Дөнйада тордыкча гыйльмең һиммәтең[3] *фазлың илә,*
Хидмәт итдең һәм чалышдың милләтеңне тәнвирә[4]
Гомереңне итдең хәсыр[5] *тәдрис тәэлиф*[6] *тәхрирә.*

---

[1] *Рәхимәһе Аллаһу рәхмәтән васигатән* – Аллаһның киң рәхмәтләре ирешсен.
[2] *Фәүт* – үлү.
[3] *Һиммәт* – тырышлык.
[4] *Тәнәүвер* – нурландыру.
[5] *Хәсыр* – багышлау.
[6] *Тәэлиф* – китап төзү, язу.

23. Хөсәен кызы Бибимаһира каберенә куелган таш, 1907 ел

Алгы ягында (калку язулы):

الحكم لله	*Әл-хөкме лилләһи*[1]
المرحومة بى بى ماهره	*әл-мәрхүмәт Биби Маһира*
حسين قزى احمدجان	*Хөсәен кызы Әхмәджан*
بيكتمروف زوجه سى	*Биктимеров зәүҗәсе*
١٩٠٧ سنده ٢٣ ياشنده	*1907 сәнәдә 23 яшендә*
وفات ٤ نويابرده بنم	*вафат 4 ноябердә бәнем*
روحمه قران اوقوب	*рухыма Коръән укыб*
باعشلاعان لرعه الله …	*багышлаганларга Аллаһ …*

24. Әсфәндияр кызы Бәдигыльҗәмал каберенә куелган таш, 1907 ел

Алгы ягында (калку язулы):

لا اله الا الله محمد رسول الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ*[2]
المرحومة بديعل جمال	*Әл-мәрхүмәт Бәдигыльҗәмал*
اسفنديار قزى	*Әсфәндияр кызы*
ابوبكر تيريعولوف	*Әбү Бәкер Терегулов*
زوجه سى	*зәүҗәсе*[3]
١٩٠٧ سنده وفات	*1907 сәнәдә вафат*

Сул ягында (калку язулы):

۴۴ ياشنده	*44 яшендә*

---

[1] *Әл-хөкму Лилләһи* – Хөкем итү Бөек, Олуг Аллаһ карамагындадыр.

[2] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.

[3] *Зәүҗәсе* – хатыны.



23=A



24=A

25=A

25. Мөхәммәдкәрим морза бине Салих Биглов каберенә куелган таш, 1908 ел

Алгы ягында (калку язулы):

كل شى	*Көлли шәййе*
هالك الا وجهه	*һаликүн иллә вәҗһәһү*[1]
بو قبرده	*бу кабердә*
محمد كريم	*Мөхәммәдкәрим*
مرضه بن صالح	*морза бине Салих*
بيغلوف قوالير	*Биглов кавалер*
پادپلكاونيك ۱۸۴۳ سنه طووب …	*подполковник 1843 сәнә туыб …*

Сул ягында (калку язулы):

۱۹۰۸ سنه ۶۵ ياشنده وفات	*1908 сәнә 65 яшендә вафат*

Үлчәмнәре: 16×30×150 см.

---

[1] *Көллү шәййин һаликүн иллә вәҗһәһү* – Һәр эштә хөкем Аллаһыга хастыр (Кара: Касас сүрәсе, 88 аять).

26. Мөфти Мөхәммәдьяр улы Арыслангали каберенә куелган таш, 1910 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

كل نفس ذائقة الموت	*Көллү нәфсин заикател-мәүт*[1]
راقد هذا القبر بحكم مالك القدر	*ракыйд һәзә әл-кабер би-хөкме мәлик әл-кадер*[2]
آرسلان على بن مفتى الاسلام الحاج	*Арслангали бине мөфти әл-ислам әл-хаҗ*
محمديار سلطانى. توفى فى تاريخ	*Мөхәммәдйар Солтани. Тәвәффә фи тарих*
٢٨ ماه شوال فى ١٣٢٨ سنة بالهجريه	*28 маһ шәүвәл фи 1328 сәнәти бил-хиҗрия*
و ١٩ اوكتابر فى ١٩١٠ سنة بالميلاديه	*вә 19 үктәбер фи 1910 сәнәти бил-милядия*
و كان عمره ٥٠ سنة نور الله قبره و جعل	*вә кянә гомреһу 50 сәнәти*[3] *нәүвәрә Аллаһу кабрәһу вә җәгалә*
روضة من رياض الجنة امين	*раузати мин риязел-җәннәти*[4]*. Амин*
وفاتى صوڭنده جنازه سى حرمتلب بيرلگان ۋينوكلر:	*вафаты соңында җәназасы хөрмәтләб бирелгән веноклар:*
غوبيرن سكى پريدۋاديتيل دۋاره ن	*губернский предводитель дворян*
آ. آ. كوغوشفدن اوفاده	*А.А. Кугушевдан Уфада*

Арткы ягында (уйма язулы):

مرحومنك نسبى	*мәрхүмнең нәсәбе*
ارسلان على	*Арыслангали*

---

[1] *Көллү нәфсин заикател-мәүт* – Һәрбер җан үлем тәмен татып караячак.

[2] *Ракыйд һәзә әл-кабер би-хөкме мәлик әл-кадер* – Аллаһы Тәгалнең хөкеме белән бу кабердә ятучы.

[3] *Вә кянә гомреһу* 50 *сәнәти* – 50 яшендә иде.

[4] *Нәүвәрә Аллаһу кабрәһу вә җәгалә раузати мин риязел-җәннәти* – Аллаһ каберен нурласын һәм актык сыену урынын җәннәт кылсын.

26=A

بن مفتى محمد يار	*бине мөфти Мөхәммәдйар*
بن محمد شريف	*бине Мөхәммәдшәриф*
بن بايزيد بن	*бине Баязид бине*
عبد الجليل بن	*Габделҗәлил бине*
سلطان	*Солтан*
ݣوبيرنسكى تورمه	*губернский төрмә*
ويده مستؤاسندن	*ведомствосендән*

Уң ягында (уйма язулы):

… من كان حيا كان يوما ميتا	*Мән кянә хәййан кянә йаүмән мәйтән*[1]
… فى الموة من ادنى الا ناس و الرتوت	…
مات ارسلانعلى لكن لم يمت آثاره	*Матә Арыслангали ләкин ләм йумит асәруһу*
انما مات المسمى و آسمه ما لا يموت	*Иннәма матә әл-мүсәммә вә исмүһу ма лә йамут*[2]

Сул ягында (уйма язулы):

انّما الدنيا فنا ء ليس للدّنيا بقاء	*Иннәма әд-дөнья фәнаүн, ләйсә ли-д-дөнья бакаун*
انّما الدنيا و ما فيها كنسج الع...	*Иннәма әд-дөнья вә ма фиһа кә-нәсҗи-л-га[нкәбут]*[3].
بانقلاب الدهرمن موت و …	*Би-инкыйлаби әд-дәһри мин мәүти вә...*
هاذم اللذات فى اعلى ندا قد …	*Һадим әл-ләззәти фи әгъля нидаи кад ...*

[1] *Мән кянә хәййан кянә йаүмән мәйтән* – Исән кеше бер көн вафат булыр.

[2] *Иннәма матә әл-мүсәммә вә исмүһу ма лә йамут* – Хакыйкатьтә үзе үлсә дә, исеме калачак.

[3] Гали бине Әбу Талиб сөйләгән шигъри юлларның үзгәртелгән варианты: *Дөнья тиз узучан, фани; анда мәңгелек [бернәрсә дә] юк. Дөньяның барча эше үрмәкүч үргән пәрәвез сыман.*

27=А

28=А

29=А

27. Еникеев Хәбибулла улы Солтан-Мөхәммәд каберенә куелган таш, 1860–1910

Алгы ягында (уйма язулы):

لا اله الا الله محمد رسول الله
ینیکییف سلطان محمد حابیبوالله اوغلی

Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ[1]
Йәнекеев Солтан-Мөхәммәд Хәбибулла углы

Еникеев Султан Хабибуллович
1860–1910

---

[1] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.

28. Шаһимәрдан Еникеев кызы Мәрзыя каберенә куелган таш, 1915 ел

Алгы ягында (калку язулы):

اکفى بالموت واعظا	*кәфә бил-мәүти вагыйзән*[1]
مرحومه مرضیه	*Мәрхүмә Мәрзыя*
شاهمردان	*Шаһимәрдан*
ینکییف قزي	*Йәникеев кызы*
سلطان بك	*Солтанбәк*
ینکییف زوجه سی	*Йәникеев зәүҗәсе*[2]

Уң ягында (калку язулы):

وفات ۱۹۱۵ سنده ۳۶ یاشنده	*вафат 1905 сәнәдә 36 яшендә*

29. Мөхәммәдшакир бине Мөхәммәдсыйддыйк Галикәев каберенә куелган таш, 1920 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

كل نفس ذائقة الموت هذا مرقد المرحوم محمد شاكر بن محمد صيديق علكايف
دار البقايه رحلت ئيتدى ٧ مارتده ١٩٢٠ سنده ٥٣ يه شنده اللهم اجعل قبره
روضة من رياض الجنة

Көллү нәфсин заикател-мәүт[3] *һәзә мәркадь әл-мәрхүм Мөхәммәд-шакир бине Мөхәммәдсыйддик Галикәев дарелбәкая рихләт итде 7 мартда 1920 сәнәдә 53 яшендә Аллаһүммә әҗгалә кабрәһу раузати мин риядел-җәннәт*

---

[1] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.
[2] *Зәүҗәсе* – хатыны.
[3] *Көллү нәфсин заикател-мәүт* – Һәрбер җан үлем тәмен татып караячак.

30=А



30=Г

31=А

30. Галиулла улы Гайфулла каберенә куелган таш, 1921 ел

Алгы ягында (калку язулы):

هو الله الباقی و	*Һуа Аллаһу әл-Бакый вә*
عداه الفانی بو قبر	*... әл-фани бу кабер*
شریف ده قویلمش عیف	*шәрифдә куелмыш Гайф-*
الله علی الله اوعلی عثمانی	*-улла Галиулла углы Госмани*
۱۹۲۱ نچی یلده ۱۷ نچی نویابر	*1921 нче елда 17 нче ноябрь*
۶۵ یاشنده طیب الله ثراه	*65 яшендә таййәбә Аллаһу сәраһү*[1]

Сул ягында (калку язулы):

استرلیتماق شهرننک معتبر سوداگر و خیرت صاحب ...

Эстәрлетамак шәһәренең могътәбәр сәүдәгәре вә хайрәт сахиб ...

[1] *Таййәбә Аллаһу сәраһү* – Аллаһ туфрагын яхшы итсен.

31. Мөхәммәдвәли кызы Биби-Сара каберенә куелган таш, 1922 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

لا اله الا الله محمد رسول الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ*
اوشبو قبرگه دفن ایدولدی	*ошбу кабергә дәфен иделде*[1]
بیبی ساره محمدولی قزی و محمد	*Биби Сара Мөхәммәдвәли кызы вә Мөхәммәд-*
شاکر زاهید اللین اهلیه سی	*шакир Заһидуллин әһлиясе*[2]
٢٨ نچی عنوارده ١٩٢٢ نچی یلده	*28 нче гыйнварда 1922 нче елда*
٤٥ یاشنده حق تعالی عَریق	*45 яшендә Хак Тәгалә гарикъ*
رحمت ایله ب قبرینی روضة من	*рәхмәт әйләб каберене раузати мин*
ریاض الجنة اله یه امین	*риядел-җәннәт*[3] *... амин*

32. Мифтахеддин улы Бәдреддин Нәзиров каберенә куелган таш, 1922 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

لا اله الا الله محمد رسول الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ*[4]
اوشبو قبرده مدفون	*ошбу кабердә мәдфүн*[5]
بدرالدین مفتاح الدین	*Бәдреддин Мифтахеддин*
اوعلی نزیرف ٥٩ یاشنده	*углы Нәзиров 59 яшендә*
٢۴ نچی اییونده ١٩٢٢ نچی یلده	*24 нче июньдә 1922 нче елда*
جناب الله غریق رحمت	*Җәнабе Аллаһ гарикъ*[6] *рәхмәт*
و باعش معفرت ایلسون	*вә багыш мәгъфирәт*[7] *әйләсен*
امین	*амин*
بحرمة سید المرسلین	*би-хөрмәт сәидел-мөрсәлин*

---

[1] *Дәфен иделде* – җирләнде.

[2] *Әһлиясе* – хатыны.

[3] *Раузати мин риядел-җәннәт* – кабере җәннәт бакчасы булсын.

[4] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.

[5] *Мәдфүн* – җирләнгән.

[6] *Гарикъ* – тирән.

[7] *Мәгъфирәт* – гафу.

32=А

33=А



34=А

Уң ягында (уйма язулы):

بار كوڭللردن جلى يومشاق سينںک قبرنک طاشى	*Бар күңелләрдән җылы йомшак синең кабрең ташы,*
شونده طامسون كوز ياشمننک ايك اچى هم تاتلسى	*Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы.*
زوجه نک شمسى روى	*зәүҗәң[1] Шәмсеруй*

Үлчәмнәре: 11×25×125 см.

33. Мулла Муса Кабкаев улы казый Гыйнаятулла каберенә куелган таш, 1856–1928

قاضى عناية الله
ابن ملا موسى كابكايف
1856–1928   ١٢٧٣ – ١٣٤٨
١٩٨٢ يل دينيه نظارتى طرفندان قويلدى[2]
Казый Гинаятулла Кабкаев

---

71 *Зәүҗәсе* – хатыны.
72 Ташның куелу датасы.

34. Мөхәммәдьяр кызы Зөләйха Терегулова каберенә куелган таш, 1881–1931

Алгы ягында (уйма язулы):

زوله یحه موحه ممه دیار قزی تیریعولئوا	*Зөләйха Мөхәммәдйар кызы Терегулова.*
۱۸۸۱ یلدا ۶ مایدا توعان	*1881 йылда 6 майда туган*
۱۹۳۱ یلدا ۱۱ ئییلده وافات	*1931 йылда 11 июльдә вафат*

35. Ризаэддин бине Фәхреддин каберенә куелган таш, 1859–1936 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

هذا مرقد	*Һәзә мәркадь*
الشيخ العالم	*әш-шәех әл-галим*
الفاضل مفتى	*әл-фазыйль мөфти*
رضاألدين	*Ризаэддин*
بن فحر الدين	*бине Фәхреддин*
توفى محرم۲۰	*тәвәффа мәрхүм 20*
سنة...هجر ...	*сәнәти ... һиҗр ...*

36. Габдеррәүф кызы Наилә Рәсүлева каберенә куелган таш, 1937 елда туган

Алгы ягында (уйма язулы):

نایله عبد الروف قزی رسولییه توعان

Нелли Расулева родилась 21 апреля 1937 ...

35=A



36=A

37

37=Г

37. Ильяс бине Әхмәдшаһ Борагани әл-Кырыми каберенә куелган таш, 1938 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

بو قبرده مدفون	*Бу кабердә мәдфүн*
باعچه سرای ننک	*Багчасарайның*
الياس بن احمدشا	*Илйас бине Әхмәдша*
بوراعانی القريمی	*Бурагани әл-Кырыми*
٢٢ ياشنده وطنن	*22 яшендә ватанын*
تاشلاب لينينگراد	*ташлаб Ленинград*
دارالفنوننده	*дарелфөнүнендә*
ليكتورلق مطبعه	*лекторлык матбага-*
چيلک هم باشقه	*-чылык һәм башка*
علمی حذمتلر ده	*гыйльми хезмәтләрдә*

Уң ягында (уйма язулы):

٨۶ ياشنده	*86 яшендә*

Сул ягында (уйма язулы):

٥٠ سنه عمرن اوتكرگه ن وفات ١٩٣٨ سنه فيورال ١٠

50 сәнә гомерен үткәргән вафат 1938 сәнә февраль10

38. Мөхәммәдшакир Заһидуллин каберенә куелган таш, 1877–1958

Алгы ягында (уйма язулы):

محمد شاكير زاهيدوللين

Мухамед-Шакир Загидуллин
1877–1958

39. Султанова Анна Семеновна, 1962 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

Султанова Анна Семеновна,
1883–1962

38=A

39

40=A

40. Мөхәммәдрәхим Чанышев кызы Маһитаб каберенә куелган таш

Алгы ягында (уйма язулы):

كفى بالموت واعظا	*Кәфә бил-мәүти вагыйзән*[1]
المرحومة ماهيتب	*әл-мәрхүмә Маһитаб*
بنت محمدالرحيم	*бинте Мөхәммәдрәхим*
چانشف ا زوجت	*Чанышева, зәүҗәте*[2]
رستم بك ينكيف	*Рөстәмбәк Йәникәев*

41. Мөхәммәдсадыйк Ваһабов улы Мөхәммәдзакир каберенә куелган таш

Алгы ягында (уйма язулы):

اوشبو قبرده مدفون اوفا عوبيرناسى زالتاوست اويازى دؤان مَسجدلى اولينڭ محمدذاكر
بن محمد صادق وهابف وفات بولدى

Ошбу кабердә мәдфүн Уфа губернасы Залтауст өязе Дуван Мәсҗедле авылының Мөхәммәдзакир бине Мөхәммәдсадыйк Ваһабов вафат булды

42. Салих исемле ятим бала каберенә куелган таш

Алгы ягында (уйма язулы):

لا اله الا الله محمد رسول الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ*[3]
بو قبر ده سوكلو بالا	*бу кабердә сөекле бала*
صالح دفن قيلندى	*Салих дәфен кылынды*
…	...

[1] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.

[2] *Зәүҗәсе* – хатыны.

[3] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.



42=А

41=А 42=Г 43=А

Сул ягында (уйма язулы):

يتيم بالا ايدى	*ятим бала иде*

43. Мөхәммәд[рәхим] каберенә куелган таш

Алгы ягында (калку язулы):

نور الله	*нәүвәрә Аллаһу*
مرقد	*мәркадь*[1]
محمد…	*Мөхәммәд[рәхим]*
…	...
…	...

[1] *Нәүвәрә Аллаһу мәркадь* – Аллаһ каберен нурласын.

44=A

45=A

44. Гатаулла Ягъкубов кызы Биби-Маһитаб каберенә куелган таш

Алгы ягында (уйма язулы):

لا اله الا الله	*Лә иләһә иллә Аллаһ*
محمد رسول الله	*Мөхәммәд рәсүлүллаһ*[1]
مدفون	*мәдфүн*
بی بی ماهی تاب	*биби Маһитаб*
عطاء الله قزی	*Гатаулла кызы*
یعقوبوا ١ نچی	*Ягъкубова 1 нче*
محله ده مؤذن	*мәхәлләдә мөәззин*
…	… [2]

[1] *Лә иләһә иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ* – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәд Аллаһның илчесе.

[2] 1892 елда вафат булуы ихтимал.

46=B (арткы як)

47=А

45. Кемгә һәм кайчан куелганы билгесез таш

Алгы ягында (уйма язулы):

روى البخارى مرفوعا ان النبى صلى الله عليه وسلم قال
يقول الله ما لعبدى المؤمن اذا قبضت
صفيه ثم احتسبه الا الجنه[1]

46. Кемгә һәм кайчан куелганы билгеле булмаган таш

Арткы ягында (уйма язулы):

بنم قبرم زياره ت ايده ن اخوان	*Бәнем кабрем зиярәт идән ихван*
قيلنك بر فاتحه روحمغه احسان	*кылың бер фатиха рухымга ихсан*

47. Кемгә һәм кайчан куелганы билгесез таш

Алгы ягында (калку язулы):

يا حنان يا منان يا حنان يا منان	*Йа-Хәннан, йа-Мәннан,*
	йа-Хәннан, йа-Мәннан[2]
…	...

Ядкяр Каргалы остасы тарафыннан ясалган дип фараз ителә.

[1] Бу урында имам Бохаридан алынган хәдис-мәрфугъ язылган.
[2] *Йа-Хәннан, йа-Мәннан* – Аллаһы Тәгаләнең асыл исемнәре.

48. Кемгә һәм кайчан куелганы билгесез таш

48=A

Мигъмари корылма рәвешендә.

كل نفس ذائقة الموت	*Көллү нәфсин заикател-мәүт*[1]
و كل من عليها فان ويبقى وجه	*вә көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһү*
ربك ذوالجلال و الا كرام	*Раббикә зөл-Җәляли вәл-Икрами*[2]

---

[1] *Көллү нәфсин заикател-мәүт* – Һәрбер җан үлем тәмен татып караячак.

[2] *Көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһү Раббикә зөл-Җәлали вәл-Икрами* – Җирдә булган бар нәрсә һәләк булачак. Фәкать олуглык һәм хөрмәт иясе булган Раббыңның заты мәңгелек.

Фоторәсемнәре бирелмәгән ташъязма истәлекләр

49. Мөхәммәдрәхим морза каберенә куелган таш, 1883 ел

Алгы ягында (калку язулы):

نور الله	*Нәүвәрә Аллаһу*
مرقد	*мәркадь*[1]
محمد رحيم	*Мөхәммәдрәхим*
مرضه بن	*морза бине*
صاليح	*Салих*

Сул ягында (калку язулы):

١٨٨٣ نچی یلده ٣٩ یاشنده	*1883 нче елда 39 яшендә*

Үлчәмнәре: 13×24×55 см.

50. Галиулла улы каберенә куелган таш, 1922 ел, 71 яшендә вафат

51. Мөхәммәдәмин кызы Мәстүрә каберенә куелган таш

Садреддин Мифтахеддин улының хатыны

---

[1] *Нәүвәрә Аллаһу мәркадь* – Аллаһ каберен нурландырсын.

Усманов Венер Мударрисович

**ТАТАРСКИЕ
ЭПИГРАФИЧЕСКИЕ ПАМЯТНИКИ
РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН**
Уфа
(на татарском языке)

Корректоры: *Е.Ф. Лукьянченко, Л.Г. Шарифуллина*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.Б. Шляпкина*

Подписано в печать 20.01.2021.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная.
Усл.-печ. л. 2,6. Уч-изд. л. 2,2. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20